

Эльвина Рустам кызы Абдеева Ләмберә районы Пензятка авылында яши. Һәм ул, шушы авылда яшәvчеләрнен кvбесе кебек, «Октябрьская» агрофирмасы бvлекчәсендә йомырка складында эшли. Бирედә кvптәннән хезмәт иткән әнисе Роза Харис кызы эзеннән киткән язма героебыз. Әтисе, Рустам Сәлижан улы да шул хужалыкта кайчандыр эшләгән.

Жирле мәктәпне тәмамлаганнан сон, пешекче-кондитер белгечлеге буенча Саранск азык-толек сәнәгате коллиятенә укырга керә Эльвина Рустам кызы. Әмма бу һонәр буенча эшләргә туры килмәгән ана.
Эльвина агрофирмада биш ел кошчы булып эшләгән. Аннары кызны яшь куллар һәм кискен кvзләргә зур ихтыяж булган йомырка складына кvчерәләр.
- Икенче ел инде йомырка складында эшлим, - дип сойли әнгәмәдәшем. Эш графигы мине канәгатьләндерә, чонки шәхси эшләр очен кvп вакыт кала: ике кон эшлим, ике кон ял итәм.
Ипотека кредитына кvпфатирлы йортта ике комнаталы квартир алган ул. Кыз әнисеннән аерым яши. Абыйсы ике бvлмәле фатирда яши: ул әбисе Ләкифә Идрис кызы Ариковадан кvчкән.
Пензятка авылында яшәv ошый, - дип дәвам итә әнгәмәне Эльвина Рустам кызы, - балалар очен менә дигән балалар бакчасы, йортлар янында уен мәйданчыклары, янәшәдә генә мәктәп, амбулатория, почта, кибетләр, клубта яшьләр очен дискотекалар оештырыла. Авылыбызда яшьләр кvп. Автобуслар бездән ерак тvгел булган башкалабыз Саранскига кадәр даими йори. Эшкә кадәр хезмәт транспорты илтеп китерә. Эш шартлары бик яхшы, халык та дус, ачык йозле. Менә шуна да мине авыл vзенә тартып тора.

**Н.ХӘЛИЛ**